# КАРАР

**“11” ноябрь 2020 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 11 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Материал сатып алу һәм зират коймаларын ремонтлау.
- Материал сатып алу һәм «Салават» чишмәсен ремонтлау.
- Урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Рөхсәтсез чүплекне юк итү.
- Уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.
- Су кудыру скважинасына насос сатып алу (2 данә).
- Амкадор хезмәтенә түләү
- Үзәк урамда авария арматуралары өчен тимер-бетон боҗралар куеп, 600 метр суүткәргеч челтәренә ремонт ясау .
- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм түшәү өчен вак таш сатып алу:
  - Үзәк, С. Халиков, Мәктәп урамнары

«ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 375 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 198 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 191 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 7 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

- Материал сатып алу һәм зират коймаларын ремонтлау.

- Материал сатып алу һәм «Салават» чишмәсен ремонтлау.

- Урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.

- Рөхсәтсез чүплекне юк итү.

-Уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

- Су кудыру скважинасына насос сатып алу (2 данә).

- Амкадор хезмәтенә түләү

- Үзәк урамда авария арматуралары өчен тимер-бетон боҗралар куеп, 600 метр суүткәргеч челтәренә ремонт ясау .

- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм түшәү өчен вак таш сатып алу:

- Үзәк, С. Халиков, Мәктәп урамнары

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Фәйзуллин